## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"10" ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 10 ноябрендә «Сез 2023 елда Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Үртәм авылындагы су башнясы будкасы өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- тимер-бетон боҗраларны сатып алу һәм урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Үртәм авылында зиратны койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары алу, хезмәтләр өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 67 (алтмыш җиде) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 43 (кырык өч) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 43(кырык өч) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2."Сез 2023 елда Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Үртәм авылындагы су башнясы будкасы өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- тимер-бетон боҗраларны сатып алу һәм урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Үртәм авылында зиратны койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары алу, хезмәтләр өчен түләү.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы: Гатауллин Р.Р.